**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**СОВЕТЫ**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 71** **2019 елның 7 ноябре**

«Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 нче статьясы, Түбән Кама муниципаль район Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2013 елның 5 мартындагы 6 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге Советы раслаган «Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә (1,2 нче кушымталар).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында, Түбән Кама муниципаль районы һәм Сосновка авыл җирлегенең рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

3. «Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен кертелгән үзгәрешләр белән Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында (РФ ТП ФДМС) урнаштырырга.


4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль район
Советының
2019 елның 7 ноябрендәге
71 номерлы карарына
1 нче кушымта




Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина

Түбән Кама муниципаль район
Советының
2019 елның 7 ноябрендәге
71 номерлы карарына
нче кушымта

## ОД-1. Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона

ОД-1 күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасы күпфункцияле кулланыштагы административ, эшлекле, иҗтимагый, мәдәни, хезмәт күрсәтүче һәм коммерция файдалану төрләрендәге киң спектрлы объектларны формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.

**Күчемсез милекнең рөхсәт ителгән төп төрләре:**

- административ-хуҗалык, эшлекле, иҗтимагый учреждениеләр һәм оешмалар;
- күпфункцияле эшлекле һәм хезмәт күрсәтүче биналар;
- **балалар бакчалары, башка мәктәпкәчә тәрбия объектлары;**
- **башлангыч һәм урта мәктәпләр;**
- мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре;
- конфессиональ объектлар;
- дини юнәлештәге уку йортлары;
- клублар;
- ачык, ябык ваклап сату базарлары;
- кибетләр;
- җәмәгать туклануы предприятиеләре;
- көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары;
- җәмәгать бәдрәфләре;
- физкультура-спорт комплекслары;
- велотреклар;
- көймә станцияләре;
- спорт мәктәпләре;
- спорт заллары, рекреация заллары (бассейнлы яки бассейнсыз), бассейннар;
- күпмаксатлы һәм махсус билгеләнештәге клублар;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- мәйданнар;
- урта махсус уку йортлары;
- укыту-җитештерү остаханәләре;
- тулай тораклар;
- элемтә предприятиеләре;
- бүлекчәләр, полициянең участок пунктлары;
- янгын депосы;
- маллар тотмый торган ветеринария хастаханәләре.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина